**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь 2021 ел** **N 1**

**«Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лелвиж авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

***1.*** 2021 елның 25 ноябренә 8 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым керту мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

***2.*** 2021 елның 25 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым керту мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

***3.*** 2021 елның 25 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым керту мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Лельвиж авылында Совет урамы, Яр буе урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру
- Совет урамындагы юлга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт) (вак таш сатып алу, ташу, җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен алмаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Лельвиж авылында су башнясы урнаштыру өчен җир кишәрлеге рәсмиләштерү;
- су башнясы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Лельвиж авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы Э.Ю. Игнатьева